ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2024 ел № 8132

Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5184 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1004 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 3755 номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 7077 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.17, 2.18 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«2.17. Муниципаль хезмәтне 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясында каралган алдан башкару (проактив) режимында күрсәтү каралмаган.

2.18. Мәгълүмати технологияләр өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мәгълүмати технологияләрдән файдаланып муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларын автоматлаштыру (машинада укыла торган тасвирлама) гамәлгә ашырылмый.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов